**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены карары**

16 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Тимбай авылында зиратны төзекләндерүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Тимбай авыл җирлегенең Тимбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимбай авыл җирлеге башлыгы _________ З.Т. Садыкова

Халык җыены секретаре _________ Г.К. Андреева